Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы

КАРАР

«08» июль 2025 ел № 124

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 31.05.2013 елның 55/1 номерлы «Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең муниципаль милке белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» гы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

2024 елның 27 декабрендәге Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен Әтнә муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тапшыру турында төзелгән килешүгә таянып, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 11.06.2025 елгы №02-08-03-2025 күрсәтмәсе нигезендә, Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 31.05.2013 елгы 55/1 номерлы «Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең муниципаль милке белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.